КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 23 июнь г.Казань № 745

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында иртәрәк ярдәм хезмәтләре күрсәтү системасын оештыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» 2019 ел, 6 сентябрь, 790 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында иртәрәк ярдәм хезмәтләре күрсәтү системасын оештыру буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» 2019 ел, 6 сентябрь, 790 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 24 февраль, 134 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Тукай һәм Биектау» сүзләрен «Әлмәт, Биектау, Алабуга, Зеленодольск, Түбән Кама һәм Тукай» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында иртәрәк ярдәм хезмәтләре күрсәтү системасын оештыру буенча пилот проектын тормышка ашыруда катнашучы иртәрәк ярдәм хезмәтләре күрсәтү белән тәэмин итүче оешмалар исемлегенә түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Перинаталь үзәге булган Әлмәт шәһәр балалар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;

«Алабуга үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;

«Зеленодольск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;

Түбән Кама шәһәренең «Перинаталь үзәге булган Шәһәр балалар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Әлмәт муниципаль районындагы «Опека» халыкка социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәге» социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесе;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алабуга муниципаль районындагы Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Астра» тернәкләндерү үзәге» социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесе;

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Зеленодольск муниципаль районындагы Мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен «Доверие» тернәкләндерү үзәге» социаль хезмәт күрсәтү дәүләт автоном учреждениесе;

Түбән Кама шәһәренең Сәламәтлегенә зур ихтыяҗ булган кешеләр өчен «Фәрештәләргә шатлык бүләк итәбез» коммерциягә карамаган автоном оешмасы;

«Сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен 19 нчы Әлмәт мәктәбе» дәүләт бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Шанс» психолог-педагогик, медицина һәм социаль ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Журавушка» 27 нче гомумүстерү төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;

Түбән Кама муниципаль районының Психолог-педагогик һәм медик-социаль ярдәмгә мохтаҗ балалар өчен «Диагностика һәм консультация бирү үзәге» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин